| ГЛАВА ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«08» ноябрь 2021 ел.

КАРАР
№ 4

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ләке авылында халык җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 18.1 ст., Сарман муниципаль районы " Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

Карары:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авылы, Тау башы урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Ләке авылы мәдәният йорты бинасында 2022 нче ёлда Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышын 2021 нче елның 19 нчы ноябрендә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, 1 Төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз картлардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда үзара салым кертүгә 300 сум күләмендә килешәсезме?:

1) Ләке авыл зираты өчен бензокосилка сатып алу;

2) Ләке авыл зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

3) Ләке авылының җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

4) Ләке авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Ләке авылы чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

6) Ләке авылы территориясендә территорияне һәм юл буе полосаларын чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

7) Ләке авылы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу;

8) Ләке авыл җирлегендә "Питрау" бәйрәме үткәрү өчен призлар, бүләкләр алу;

«РИЗА » « КАРШЫ»

3. Ләке авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http://sarmanovo.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) хэм Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 7 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Л.И.Шәрипова